ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

17 04 2023 г. № 315

«2017 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында» Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бала туу һәм тәрбияләү белән бәйле айлык пособие билгеләү һәм түләү тәртибе турында» 2022 елның 16 декабрендәге 2330 номерлы карары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставының 75 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «2017 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында» Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтаны яңа кушымта итеп бирелә торган редакциядә расларга.

2. Түбән Кама муниципаль районы Мәгариф идарәсе карамагындагы гомуми белем бирү оешмалары укучыларында барлыкка килгән бушлай туклану хокукы, әлеге карар кабул ителгәнче, элек билгеләнгән ташламаның гамәлдә булган бөтен чорына саклана дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә үз көчен җәелдерә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы А.Х. Гарифуллинга йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф.Булатов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «17» ________
315 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында социаль яктан якланмаган гаиләләрдәге укучыларны тукландыруны оештыру тәртибе турында НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында социаль яктан якланмаган гаиләләрдәге балаларны бушлай туклан-дыруны оештыру максатларында эшләнгән.

2. Түбәндәге категория укучылары бушлай туклану хокукына ия:

- ятим балалар һәм опека (попечительлек) астында булган балалар;
- инвалид балалар;
- Чернобыль АЭСындагы авария нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан гаилә бала-лары;
- 18 яшькә кадәр 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күпбалалы гаилә балалары;
- җан башына уртача керемнәре Республикада билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган азкеремле гаилә балалары;
- авыр тормыш хәленә эләккән социаль яктан якланмаган гаилә балалары.

3. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында санап үтелгән укучыларны бушлай тукландыруны оештыру өчен, гомуми белем бирү оешмасында комиссия төзелә, аның составына директор, укучыларны тукландыруны оештыру өчен җаваплы учреждениенең вазыйфаи заты, гомуми белем бирү оешмасының педагогик һәм административ составындагы башка затлар керә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны ким дигәндә җиде кеше булырга тиеш.

Кирәк булганда комиссия:

- утырыш үткәрә;
- тәкъдим ителгән документларны карый һәм бушлай туклану мөмкинлеге турында карар кабул итә;
- укучыларның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) утырышка чакырырга хокуклы.

Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының гомуми санының өчтән ике өлеше булса, хокуклы дип санала. Комиссия карары утырышта катнашу-чы әгъзалар санының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашучы комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм комиссия рәисе тарафын-нан утырыш уздырылган көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча раслана.

4. Бушлай туклану хокукына ия булган гомуми белем бирү оешмасының укучылар исемлеген учреждение директоры раслый.

5. Бушлай туклану хокукы бирү өчен кирәкле документлар исемлеге:

5.1. Әлеге Нигезләмәгә кушымтада бирелгән форма буенча кәгазь чыганакта документ формасында гариза.

5.2. Гаризага кушып тапшырыла:

5.2.1. Ятим балалар һәм опека (попечительлек) астында булган балалар категориясе өчен:

- гариза бирүче паспортының күчермәсе;
- балада ятим яки ата-ана каравыннан мәхрүм калган бала статусы булу турында опека һәм попечительлек органнарыннан белешмә.
- балигъ булмаган укучыга опека (попечительлек) билгеләү турында боерык күчермәсе.

5.2.2. Инвалид балалар категориясе өчен:

- гариза бирүче паспорты күчермәсе;
- медицина-социаль экспертизаның медицина белешмәсе күчермәсе.

5.2.3. Чернобыль АЭСында авария нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан гаилә балалары категориясе өчен:

- гариза бирүче паспорты күчермәсе;
- Чернобыль АЭСында авария нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы ата-ана таныклыгының күчермәсе.

5.2.4. 18 яшькә кадәр 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күпбалалы гаилә балалары категориясе өчен:

- гариза бирүче паспорты күчермәсе;
- күпбалалы гаилә таныклыгы күчермәсе;
- һәр балага туу турында таныклык күчермәсе.

5.2.5. Җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән халыкның җан башына яшәү минимумы күләменнән түбән булган азкеремле гаилә балалары категориясе өчен:

- гариза бирүче паспорты күчермәсе;
- һәр балага туу турында таныклык күчермәсе;
- гаилә составын һәм балаларның яшәү урыны буенча гражданнарны теркәү турында мәгълүматны раслаучы документ;
- социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасында граждан турында, социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында социаль хезмәтләр күрсәтү, социаль яклау (ярдәм) чаралары, башка социаль гарантияләр турында, шулай ук ата-ананың бала туу һәм тәрбияләү белән бәйле айлык пособие алучы статусына ия булуын раслый торган, гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы субъектында билгеләнгән халыкның җан башына яшәү минимумы күләменнән артмаган исәптән билгеләнгән түләүләр һәм башка бүләкләүләр турында мәгълүматлар.

Әлеге пунктта каралган укучылар категориясенә бушлай туклану хокукы гариза бирүчегә югарыда күрсәтелгән абзацта билгеләнгән бала туу һәм тәрбияләү белән бәйле рәвештә пособие алу чорына бирелә.

5.3. Авыр тормыш хәленә эләккән социаль яктан якланмаган гаилә укучылары, учреждениегә кергән балигъ булмаган укучының авыр тормыш хәлен раслаучы «Түбән Кама муниципаль районында «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге» ДАСХКУ яки «Түбән Кама муниципаль районында

«Балкыш» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют» ДКУ үтенече булган очракта, гомуми белем бирү оешмасы тарафыннан бушлай туклану белән тәэмин ителә.

6. Сыйныф җитәкчеләре:

- укучыларның ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән), кирәкле документлар теркәп, бушлай туклану хокукы бирүгә гаризалар кабул итәләр;

- гаризаларны һәм кушымта итеп бирелгән документларны әлеге Нигезләмәнең 3 пункты нигезендә гомуми белем бирү оешмасында төзелгән комиссиягә аларны алганнан соң өч көн эчендә карауга җибәрәләр.

7. Авыр тормыш хәленә эләккән социаль яктан якланмаган балалар категориясенә карата гомуми белем бирү оешмасына кергән «Түбән Кама муниципаль районында «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге» ДАСХКУ яки «Түбән Кама муниципаль районында «Балкыш» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют» ДКУ үтенечләре учреждение директоры тарафыннан 1 эш көне дәвамында комиссия каравына җибәрелә.

8. Ата-аналар (законлы вәкилләр) тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

9. Гомуми белем бирү оешмасы директоры:

9.1. Комиссия протоколы нигезендә, комиссия утырышыннан соң 1 эш көне эчендә категорияләр буенча укучыларга бушлай туклану хокукы бирү турында боерык чыгара.

9.2. 3 эш көне дәвамында бушлай туклану хокукына ия булган гомуми белем бирү оешмасы укучылары исемлеген раслый;

9.3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә, Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасы базасына кертү өчен, бушлай туклануга хокуклы гомуми белем бирү оешмасы укучылары исемлеген тапшыралар.

10. Түбән Кама муниципаль районы Башкирам комитетының Мәгариф идарәсе Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасы базасын алып баруны тәэмин итә.

Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында социаль яктан якланмаган гаиләләрдәге укучыларны тукландыруны оештыру тәртибе турында нигезләмәгә кушымта

(Форма)

«_________________ _____ мәктәп»
МБББУ директорына
____________________________________
(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. ис.)

____________________________________
(адрес)

гариза.

______ сыйныф укучысы минем улым (кызым, опекага алынган бала) ______________________________________________________________
(Ф.И.А.ис.)

бушлай туклану хокукы бирүегезне үтенәм.

Нигез ______________________________________________________.
бушлай туклану хокукы булган укучы категориясе күрсәтелә

Өстәмә хәбәр итәм: ______________________________________
____________________________________________________________.

Гаризага терким:

1. ______________________________;
2. ______________________________;
3. ______________________________;
4. ______________________________.

__________________________
(Дата, имза)